КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1366

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кайбер социаль хезмәт күрсәтү оешмалары койка фондын билгеләү турында» 2015 ел, 17 апрель, 257 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кайбер социаль хезмәт күрсәтү оешмалары койка фондын билгеләү турында» 2015 ел, 17 апрель, 257 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 6 март, 119 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып), 1 пунктның икенче – җиденче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Яңа Чүриле интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 413 койка-урын күләмендә;

«Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Алабуга интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 460 койка-урын күләмендә;

«Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Зеленодольск интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 544 койка-урын күләмендә;

«Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Чистай интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 286 койка-урын күләмендә;

«Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Казан интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 337 койка-урын күләмендә;

«Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Кама Аланы интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 440 койка-урын күләмендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин